КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1433

2023 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы, «2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2022 елның 5 декабрендәге 466-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чираттагы елга Россия Федерациясе субъектларында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 26 июнендәге 1022 номерлы карары, «Татарстан Республикасында яшәү минимумы турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2022 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 12 219 сум, эшкә яраклы халык өчен – 13 319 сум, пенсионерлар өчен – 10 508 сум, балалар өчен – 11 852 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин